**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 4 февраль № 61

г. Казань

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Чаллы» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү хакында» 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын түбәндәгеләр буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы дип билгеләргә:

алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары реестрын алып бару буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы белән үзара хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыру;

алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү.

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибен (алга таба – Тәртип) һәм аның бертип формасын расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\61.doc

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган моношәһәрнең алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү тәртибенә 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган моношәһәрнең алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаның бертип формасы**

«__________________________________________________________»
алга киткән үсеш территориясе исеме

алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә
эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә
ГАРИЗА

_______________________________________________________________ нигезендә эш итүче
__________________________________________________________________________ йөзендә
(вазыйфа, Ф.И.Ат.и.)

__________________________________________________________________________________
(юридик зат исеме)

«__________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гариза җибәрә һәм гаризаның «Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре хакында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «______________________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» _______ ел, _________, ______ карары таләпләренә туры килүен раслыйм.

Гаризага таләп ителә торган материаллар теркәлә. Мәгълүматларның дөреслеген гарантиялим.

Кушымта:

| | | | |
|---|---|---|---|
| Җитәкче | _______________ | __________________ / | _________________ |
| | (дата) | (имза) | (Ф.И.Ат.и.) |

М.У.*

------------------------------
* Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта.

Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган моношәһәрнең алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзүгә гаризаларны карап тикшерү тәртибенә 2 нче кушымта

## Инвестицион проект паспорты

Гариза бирүче турында мәгълүмат:

| | |
|---|---|
| Тулы һәм кыскартылган исеме | |
| Оештыру-хокукый формасы | |
| Теркәү датасы | |
| Теркәү урыны | |
| Гамәлдә урнашкан урыны | |
| Милекчеләр (моношәһәрнең шәһәр төзү оешмасы белән бәйләнеше булмау турындагы мәгълүматны кертеп) | |
| ОКВЭД буенча кодларны күрсәтеп, төп икътисадый эшчәнлек төрләре | |
| Соңгы 3 елга эшчеләрнең исемлек буенча уртача саны | |
| Дәүләт ярдәме булу/булмау һәм аның формалары | |
| Махсус салым режимын куллану | |
| шәхси тәңгәлләштерү саны (ИНН) | |
| төп дәүләт теркәү саны (ОГРН) | |
| исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| Элемтәгә керү өчен зат | |
| Телефон | |
| Электрон почта адресы | |

Инвестицион проект турында мәгълүмат:

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Инвестицион проект (ИП) исеме | |
| 2 | ОКВЭД нигезендә ИП буенча икътисадый эшчәнлек төре | |
| 3 | ИП гамәлгә ашыру урыны | |
| 4 | ИП характеры («нульдән» төзү, төзекләндерү, модернизацияләү, гамәлдәге производствода яңа продукция чыгару, гамәлдәге производствоны киңәйтү, башкасы) | |
| 5 | ИП максаты һәм, табигый һәм кыйммәти чагылышта проектның еллык куәтен күрсәтеп, асылының кыскача тасвирламасы | |
| 6 | Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш бурычларына, тармак үсеш стратегияләре (программалар, концепцияләр) өстенлекләренә ИП туры килүен нигезләү, аларны раслау турында тиешле норматив хокукый актларны күрсәтеп | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | ИП гамәлгә ашыру вакытлары (төп капиталга инвестицияләр кертү чоры), шул исәптән төп этаплары: | | |
| 7.1 | инвестицияләр алды тикшеренүләре, проект документларын/бизнес-план эшләү | | |
| 7.2 | килештерү һәм рөхсәт бирә торган документларны алу | | |
| 7.3 | төзү | | |
| 7.4 | җиһазлар сатып алу һәм кайтарту | | |
| 7.5 | проектны башлау (эксплуатациягә кертү) | | |
| 7.6 | проект куәтенә чыгу | | |
| 8 | ИП эшләнеш дәрәҗәсе (ИП гамәлгә ашыру кирәклеге турында карар кабул итү датасы һәм дәрәҗәсе, проект документларының әзерлек дәрәҗәсе (дәүләт экспертизасы бәяләмәләре булу), ИП гамәлгә ашыру буенча элегрәк үткәрелгән һәм хәзерге вакытта тормышка ашырыла торган чаралар, ИП гамәлгә ашыру кысаларында күрсәтелгән дәүләт ярдәме формасы булу) | | |
| 9 | ИП гомуми кыйммәте (ӨКС белән), млн.сум | | |
| 10 | ИП финанслауның тәэмин ителеш дәрәҗәсе (финанслауның документлар белән расланган чыганаклары), ИП гомуми кыйммәтеннән % | | |
| 11 | Инвестицион чыгымнар структурасы һәм аларны үзләштерү дәрәҗәсе: | Бәясе, мең сум | Планлаштырылган күләмнән кертелгән акча өлеше, % |
| 11.1 | капиталь чыгымнар, шул исәптән: | | |
| 11.1.1 | проектлаштыру | | |
| 11.1.2 | җир сатып алу | | |
| 11.1.3 | төп чаралар сатып алу | | |
| 11.1.4 | төзү-монтажлау эшләре | | |
| 11.1.5 | җиһазлар сатып алу | | |
| 11.1.6 | инвестицион фазада башка чыгымнар | | |
| 11.2 | әйләнештәге капиталга инвестицияләр | | |
| 12 | ИП өчен таләп ителә торган инфраструктура, ресурслар һәм аларның булуы, шул исәптән: | | |
| 12.1 | күрсәтелгән икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган җир кишәрлеге мәйданы яки мөлкәт | | |
| 12.2 | гариза бирүченең энергия кабул итү җайланмаларының кирәкле кушыла торган куәте күләме, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү хезмәтләре күрсәтү өчен файдаланыла торган кирәкле ресурларга (шул исәптән суык һәм кайнар су, челтәр газы һәм җылылык энергиясенә), шулай ук эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка ресурсларга карата ялгана торган кирәкле йөкләнеш төрләре, күләмнәре һәм планлаштырыла торган зурлыгы, аларның булуы | | |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | ИП гамәлгә ашырганда булган проблемалар (ресурслар җитмәү, җир кишәрлеген бүлеп бирү/сатып алу, финанслауның җитмәве, инфраструктура (тышкы инфраструктура объектларын кертеп) булмау/җитмәү, сату базары булмау, оештыру мәсьәләләре һ.б.) һәм аларны хәл итү буенча тәкъдимнәр | |
| 14 | Потенциаль инвесторлар һәм партнерлар белән хезмәттәшлек итүнең мөмкин булган формалары (технологияләр трансферы, инжиниринг; җиһаз кайтартучылар эзләү; сату базарларын киңәйтү; өлешле финанслау; бурычка финанслау; гарантия бирү (поручительлек), һ.б.) | |
| 15 | Кредит акчасын (банк гарантиясе, поручительлек, залог, башкасы) җәлеп иткән очракта, ИП буенча тәэмин ителеш булу | |
| 16 | Дәүләт һәм үстерү институтлары тарафыннан ярдәм күрсәтүнең күздә тотылган формасы | |
| 17 | ИП финанс-икътисадый, бюджет һәм социаль нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре: | |
| 17.1 | чиста дисконтлы табыш (NPV), млн.сум | |
| 17.2 | чыгымнар капланунның гади вакыты, ел | |
| 17.3 | чыгымнар капланунның дисконтлы вакыты, ел | |
| 17.4 | табышларның эчке нормасы (IRR), % | |
| 17.5 | проект куәтенә чыкканда бер елга ИП тарафыннан булдырыла торган өстәмә кыйммәт, млн.сум (салым салганчы булган табыш, бурыч йөкләмәләре буенча процентлар түләү һәм амортизация буенча түләүләр + хезмәткәрләрнең кушылган эш хакы + аренда түләве) | |
| 17.6 | проект куәтенә чыкканда бер елга Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым керемнәре күләме, мең сум | |

Җитәкче ________________ ____________________ /________________

(дата) (имза) (Ф.И.Ат.и.)

М.У.*

------------------------------

* Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта.

# Инвестицион проектның төп күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч | Еллар | | | | | | | | | | | Бар-лыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2016 | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | 2026 | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
| 1 | **Даими эш урыннары булдыру планы, кеше** | | | | | | | | | | | | |
| 2 | **ИП гамәлгә ашыру еллары буенча инвестицияләр кертү, млн.сум, шул исәптән:** | | | | | | | | | | | | |
| 2.1 | үз акчасы (керем, амортизация) | | | | | | | | | | | | |
| 2.2 | җәлеп ителә торган акча, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| 2.2.1 | банклар кредитлары | | | | | | | | | | | | |
| 2.2.2 | федераль бюджет акчасы | | | | | | | | | | | | |
| 2.2.3 | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | | | | | | | | | | | | |
| 2.3 | чит ил инвестицияләре, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| 2.3.1 | туры чит ил инвестицияләре | | | | | | | | | | | | |
| 3 | **Табыш күләме, мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| 4 | **Керем күләме, мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| 5 | **Иминият кертемнәре, мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| 5.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчере-лергә тиеш | | | | | | | | | | | | |
| 5.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш[1] | | | | | | | | | | | | |
| 6 | **Өстәмә кыйммәткә салым, мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| 7 | **Табышка салым, мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| 7.1 | федераль бюджетка, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| 7.1.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчере-лергә тиеш[2] | | | | | | | | | | | | |
| 7.1.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш[3] | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7.2 | Татарстан Республикасы бюджетына, шул исәптән: | | | | | | | | | | | | |
| 7.2.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш [4] | | | | | | | | | | | | |
| 7.2.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш [5] | | | | | | | | | | | | |
| 8 | **Физик затларның keремнәренә салым (НДФЛ), мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| 8.1 | Татарстан Республикасы бюджетына | | | | | | | | | | | | |
| 8.2 | муниципаль берәмлек бюджетына | | | | | | | | | | | | |
| 9 | **Оешмалар мөлкәтенә салым, мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| 9.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш | | | | | | | | | | | | |
| 9.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш [6] | | | | | | | | | | | | |
| 10 | **Җир салымы, мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| 10.1 | ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш | | | | | | | | | | | | |
| 10.2 | ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш [7] | | | | | | | | | | | | |
| 11 | **Транспорт салымы, мең сум** | | | | | | | | | | | | |
| **Салымга түләнгән акчалар буенча барлыгы** | | | | | | | | | | | | | |
| 12 | Иминият кертемнәре буенча барлыгы (5.1 п.– 5.2 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 13 | Федераль бюджетка ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш (6 п. + 7.1.1 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 14 | Федераль бюджетка ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш (6 п.+ 7.1.2 п.) | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Россия Федерациясенең алынып бетмәгән керемнәре (13 п.– 14 п.– 12 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 16 | Россия Федерациясе буенча барлыгы (14 п.– 15 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 17 | Татарстан Республикасы бюджетына ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш (7.2.1 п.+ 8.1 п.+ 9.1 п.+ 11 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 18 | Ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш (7.2.2 п.+ 8.1 п.+ 9.2 п.+ 11 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 19 | Татарстан Республикасының алынып бетмәгән керемнәре (17 п.– 18 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 20 | Татарстан Республикасы буенча барлыгы (18 п.– 19 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 21 | Муниципаль берәмлек бюджетына ташламаларны исәпкә алмыйча күчерелергә тиеш (8.2 п.+ 10.1 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 22 | Муниципаль берәмлек бюджетына ташламаларны исәпкә алып күчерелергә тиеш (8.2 п.+ 10.2 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 23 | Муниципаль берәмлекнең алынып бетмәгән керемнәре (21 п.– 22 п.) | | | | | | | | | | | | |
| 24 | Муниципаль берәмлек буенча барлыгы (22 п.– 23 п.) | | | | | | | | | | | | |

[1] Салым суммасы 7,6 процент ставкасы буенча исәпләнә. Әлеге ташлама юридик зат алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе (алга таба – АКСИҮ территориясе) резиденты статусын алган көннән 10 ел дәвамында тарала. Миминият кертемнәренең ташлама тарифлары әлеге статусны АКСИҮ территориясен төзегән көннән 3 елдан да соңга калмыйча алган резидентларга мөнәсәбәтле кулланыла.

[2] 2 процент күләмендәге салым ставкасы буенча исәпләнгән салым суммасы.

[3] Салым исәбе мәгълүматлары нигезендә АКСИҮ территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән беренче табыш алынган салым чорыннан башлап, 5 салым чоры дәвамында 0 процент күләмендә салым ставкасы.

[4] 18 процент күләмендәге салым ставкасы буенча исәпләнгән салым суммасы.

[5] Салым исәбе мәгълүматлары нигезендә АКСИҮ территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне үтәгәндә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән беренче табыш алынган салым чорыннан башлап, беренче 5 салым чоры дәвамында салым ставкасы – 5 процент күләмендә, киләсе 5 салым чоры дәвамында – 10 процент күләмендә.

[6] Оешма балансында исәпкә алына торган мөлкәткә карата ставка мөлкәтне исәпкә алган вакыттан 10 ел дәвамында 0 процент күләмендә билгеләнә.

[7] Ставка 0 процент күләмендә билгеләнә.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Җитәкче | __________________ | ____________________ / | _________________ |
| | (дата) | (имза) | (Ф.И.Ат.и.) |
| | | М.У.* | |

-------------------------------

* Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта.

F:\KARAR\2016\61_3.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән расланды

Бертип форма

**«___________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү**

______________ «___» ___________ 20__ ел

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә эш итүче _____________________ йөзендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык), Низамнамә нигезендә эш итүче «____________________» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе _______________________________________ йөзендә Татарстан Республикасы «_________________» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) һәм __________________ нигезендә эш итүче ____________ йөзендә алга таба «Резидент» дип аталучы _________________, алга таба – «Яклар», аерым алганда «Як» дип аталучылар, «Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «______________________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясен төзү турында» _______ ел, _________, _______ карары (алга таба – норматив документлар) нигезендә әлеге «_______________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүне (алга таба – Килешү) түбәндәгеләр турында төзедек:

## 1. Килешү предметы

1.1. Резидент үзе керткән Килешү төзүгә гариза һәм әлеге Килешүгә теркәлгән 1 нче кушымтага ярашлы рәвештә инвестицион проектны тормышка ашыру планы нигезендә, бу Килешүдә һәм норматив документларда күздә тотылган шартларда, «________________ ___________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә (алга таба – алга киткән үсеш территориясе)

____________________________________ икътисадый эшчәнлек төрләре буенча «__________________________________» яңа инвестицион проектын (алга таба – инвестицион проект) гамәлгә ашыру йөкләмәсен үз өстенә ала.

## 2. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

2.1. Әлеге Килешү Яклар тарафыннан кул куелган вакыттан үз көченә керә һәм алга киткән үсеш территориясе гамәлдә булган чорда көчендә була.

## 3. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Министрлык, Башкарма комитет һәм Резидент Килешүнең тулы күләмдә үтәлүенә булышлык күрсәтү йөкләмәсен үз өстенә алалар, һәм моның өчен кирәк булган очракта Килешүнең үтәлешенә каршылыклар тудырган хәлләр турында бер-берсенә хәбәр итәчәкләр һәм аның үтәлеше буенча килешенгән гамәлләр кылачаклар.

3.2. Министрлык, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары белән расланган Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары реестрын алып бару кагыйдәләре нигезендә, Резидентның Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары реестрына кертелүенә булышлык күрсәтү йөкләмәсен үз өстенә ала.

3.3. Башкарма комитет инвестицион проектның гамәлгә ашырылуына булышлык күрсәтү, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең мәнфәгатьле башкарма органнары белән берлектә, Резидент тарафыннан инвестицион проектның үтәлешенә булыша торган норматив хокукый актларны әзерләүне һәм үз вакытында кабул итүне тәэмин итү йөкләмәсен үз өстенә ала.

3.4. Министрлык һәм Башкарма комитет Килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлеше барышы турында Резиденттан мәгълүмат соратып алырга хокуклы.

3.5. Резидент түбәндәгеләргә бурычлы:

3.5.1. Әлеге Килешү шартларын һәм норматив документлар нигезләмәләрен үтәргә;

3.5.2. Бу Килешүгә теркәлгән план нигезендә инвестицион проектның тормышка ашырылуын тәэмин итәргә;

3.5.3. Инвестицион проектны тормышка ашыруга ___________________________________________ (суммасы сүзләр белән) млн.сум күләмендә капитал кертемнәре (шулардан кимендә 5 (биш) млн.сум әлеге Килешүне төзегән көннән беренче елны) җәлеп итәргә, шул исәптән:

3.5.3.1. Үз акчасы ________________________ (суммасы сүзләр белән) млн.сум күләмендә, яки инвестицион проектның гомуми кыйммәтеннән ___ процент;

3.5.3.2. Җәлеп ителгән акча ________________ (суммасы сүзләр белән) млн.сум күләмендә, яки инвестицион проектның гомуми кыйммәтеннән ___ процент;

3.5.4. Проектны тормышка ашыру барышында кимендә _____________ (саны сүзләр белән) яңа эш урыны, шул исәптән кимендә 20 (егерме) яңа эш урынын әлеге Килешүне төзегән көннән беренче ел дәвамында булдыруны тәэмин итәргә, шулай ук бу Килешүгә кул куйган көнгә Резидентның исемлек буенча уртача хезмәткәрләр санының кимендә 90 процентын әлеге Килешү көчендә булу чорында саклауны тәэмин итәргә;

3.5.5. Министрлыкка һәм Башкарма комитетка ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, тиешле рәвештә таныкланган раслый торган документларны теркәп, түбәндәгеләрне кертергә:

3.5.5.1. бу Килешүгә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча Килешүне үтәү турында хисап мәгълүмат;

3.5.5.2. Министрлык раслаган форма буенча Килешүне үтәү турында хисап мәгълүмат;

3.5.5.3. әлеге Килешүнең 4.1.1 нче пунктында каралган йөкләмәләр булмау турында белешмә;

3.5.6. бу Килешүнең 4.1.1 нче пунктында күздә тотылган йөкләмәләр барлыкка килү турында Министрлыкка һәм Башкарма комитетка әлеге йөкләмәләр барлыкка килгән вакыттан 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;

3.5.7. резидент буларак үз хокукларыңны һәм бурычларыңны башка затларга тапшырмаска;

3.5.8. Министрлыкка һәм Башкарма комитетка Килешү шартларының үтәлешен тикшерүдә тоту өлешендә булышлык күрсәтергә, шул исәптән Министрлык һәм Башкарма комитет вазыйфаи затларының Резидентныкы булган инфраструктура объектларына һәм алга киткән үсеш территориясендә урнашкан объектларга тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итәргә;

3.5.9. Министрлыкка һәм Башкарма комитетка тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны тиешле сорату алган көннән 5 (биш) эш көне эчендә язма рәвештә кертергә.

## 4. Килешүне өзү тәртибе

4.1. Килешүне өзү Якларның ризалыгы яки суд карары буенча рөхсәт ителә. Якларның берсе Килешү шартларын җитди бозуга, шартларның шактый үзгәрүенә бәйле рәвештә яки норматив документларда каралган башка нигезләрдә Килешү башка Як таләбе буенча суд тарафыннан өзелә ала.

4.1.1. Резидентның Килешү шартларын җитди бозу булып түбәндәгеләр тора:

а) Резидентның норматив документларда каралган таләпләргә туры килмәве;

б) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик зат – Резидент ябылу процессында тора дигән язма кертү;

в) Россия Федерациясе Граждан кодексы нигезендә үзгәртеп оештыру юлы белән юридик затның – Резидентның эшчәнлеген туктатуы;

г) законлы көченә кергән юридик затны – Резиденты банкрот дип тану турында суд карары;

д) норматив документлар белән расланган, Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары гамәлгә ашыра торган инвестицион проектларга булган таләпләрне үтәп, аны тормышка ашыру мөмкинлеген калдырмый торган, Килешүдә каралган инвестицион проект параметрларның үзгәрүе;

е) Резидентның Килешү шартларын үтәмәве;

ж) Резидент инициативасы.

## 5. Килешү Яклары җаваплылыгы

5.1. Яклар Россия Федерациясе законнары нигезендә Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәү өчен җавап тота.

5.2. Килешү өзелгән очракта, аны үтәүгә бәйле рәвештә Резидент күтәргән чыгымнар кайтарылмый.

5.3. Килешү буенча йөкләмәләрен үтәмәгән яки аларны тиешенчә үтәмәгән Резидент шулай ук Россия Федерациясе законнары һәм Килешүдә каралган башка төрле җавап тота.

5.4. Әгәр Килешү буенча йөкләмәне үтәмәү каршы тора алмаслык көч аркасында килеп чыккан булса, Яклар Килешү шартларын үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

## 6. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

6.1. Яклар арасында барлыкка килергә мөмкин булган Килешү буенча барлык бәхәсләр һәм каршылыклар Яклар тарафыннан дәгъвалар тәртибендә (судка кадәр) хәл ителәчәк.

6.2. Бәхәсләрне сөйләшүләр юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, Яклар аларны суд каравына җибәрә.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Килешүдә каралмаган барлык очракларда Яклар Россия Федерациясе законнарына таянып эш итә.

7.2. Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр алар язма рәвештә эшләнде һәм аларга барлык Яклар кул куйды дигән шартта гына хакыйкый була.

7.3. Әлеге Килешү һәр Якка берешәр, тигез юридик көчкә ия 3 (өч) нөсхәдә төзелде.

7.4. Килешүдә күрсәтелгән барлык вакытлар, әгәр башкасы ачык күрсәтелмәсә, календарь вакытлары була.

7.5. Барлык хәбәрнамәләр һәм хәбәрләр язма рәвештә җибәрелергә тиеш. Әгәр хәбәрләр заказлы хат буларак, факс буенча җибәрелсә яки Якларның почта адреслары (факс номерлары) буенча алу турында шәхси имза куйдырып тапшырылса, алар тиешле рәвештә үтәлгән дип санала.

| | | |
|---|---|---|
| **Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы** | **Татарстан Республикасы «____________________» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты** | **Резидент:** |
| ________________________ | ________________________ | ________________________ |
| «____»___________20___ ел. | «____»_____________20___ел. | «____»__________20___ел. |

«______________________________»
алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында 2016 ел, _________, ______ килешүгә 1 нче кушымта

**«__________________________________________________»**
**инвестицион проектын гамәлгә ашыру планы**

| Күрсәткечләр | 1 нче ел | 2 нче ел | 3 нче ел | n нчы ел |
|---|---|---|---|---|
| 1. Инвестицион проектны гамәлгә ашыра башлаганнан капитал кертемнәре күләме, мең сум | | | | |
| 2. Инвестицион проектны гамәлгә ашыра башлаганнан яңа эш урыннары булдыру, берәмлек | | | | |

**Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы**

________________________
«____»__________20___ ел.

**Татарстан Республикасы «______________________» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты**

________________________
«____»____________20___ел.

**Резидент:**

________________________
«____»_________20___ел.

«_____________________________»
алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында 2016 ел, _________, ______ килешүгә 2 нче кушымта

«_______________________» алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешү йөкләмәләрен үтәү хакында мәгълүмат

_____________________________________________________
(Резидент исеме)

_____________________________
(хисап елы)

1. Инвестицион проект исеме ________________________________________________
2. Инвестицион проектны гамәлгә ашыра башлау _________________________________
3. Инвестицион проект буенча капитал кертемнәре күләме _______________________
4. Инвестицион проект буенча исемлек нигезендә уртача сан ____________________, шул исәптән инвестицион проект буенча яңа эш урыннары булдыру _______________

| Т/с | Күрсәткечләр | Хисап чорына план | Факт |
|---|---|---|---|
| 1 | Булдырылган даими эш урыннары саны, кеше | | |
| 2 | Капитал кертемнәре күләме, мең сум | | |

Җитәкче _________________ ___________________/_______________
(дата) (имза) Ф.И.Ат.и.

М.У.*

------------------------------
* Россия Федерациясе законнары нигезендә мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракта.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 февраль, 61 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) территориясендә төзелә торган алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү (алга таба тиешенчә – алга киткән үсеш территориясе, Килешү) механизмын билгели.

2. Килешү төзү өчен, алга киткән үсеш территориясендә яңа инвестицион проект гамәлгә ашырырга һәм алга киткән үсеш территориясе резиденты статусын алырга нияте булган, «Россия Федерациясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 ел, 29 декабрь, ФЗ-473 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территорияләрен төзү үзенчәлекләре турында» 2015 ел, 22 июнь, 614 нче карары, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары һәм территориясендә әлеге юридик зат үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашырырга планлаштыра торган алга киткән үсеш территориясен төзү турындагы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән алга киткән үсеш территориясе резидентларына һәм алар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инвестицион проектларга булган таләпләргә җавап бирә торган, алга киткән үсеш территориясендә теркәлгән юридик зат (алга таба тиешенчә – норматив документлар, Гариза бирүче) территориясендә алга киткән үсеш территориясе төзелә торган Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлеге (моношәһәре) башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча Килешү төзүгә гариза (алга таба – Гариза) тапшыра.

3. Гариза бирүче Гаризага түбәндәге документларын терки:

а) әлеге Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча инвестицион проект паспорты;

б) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1999 ел, 7 май, 284 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында инвестицион проектларны гамәлгә ашыручы предприятеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә теркәлгән 3 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча инвестицион проектның бизнес-планы;

в) гамәлгә кую документлары күчермәләре;

г) юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы шаһәдәтнамәнең тиешле

рәвештә таныкланган күчермәсе;

д) салым органында исәпкә кую турындагы шаһәдәтнамәнең тиешле рәвештә таныкланган күчермәсе;

е) Гариза бирүчегә карата Россия Федерациясе законнары нигезендә юридик затның акчасызлыгы (банкротлыгы) һәм (яки) аны үзгәртеп оештыру яисә ябу турында эш кузгатылган булмау хакында тиешле рәвештә таныкланган белешмә;

ж) Гариза бирүченең Россия Федерациясе дәүләт бюджеттан тыш фондларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәренең вакытында түләнми калган өлеше, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында тиешле рәвештә таныкланган белешмә;

з) Гариза бирүчене гамәлгә куючылар составында территориясендә алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясе төзелә һәм Гариза бирүченең инвестицион проекты гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлегенең (моношәһәренең) (алга таба – Моношәһәр) шәһәр төзү оешмасы яисә аның бүлекчәләре һәм бүлендек предприятиеләре булмауны раслый торган документ;

и) Гариза бирүченең инвестицион проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә Моношәһәрнең шәһәр төзү оешмасы яки аның бүлендек предприятиеләре белән төзелгән контрактларны үтәү күздә тотылмаганны һәм (яки) Гариза бирүченең инвестицион проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелгән (күрсәтелгән) товарларны (хезмәтләрне) сатудан алына торган барлык керемнең 50 процентыннан арткан күләмдә товарлар сатудан, Моношәһәрнең шәһәр төзү оешмасына яки аның бүлендек предприятиеләренә хезмәтләр күрсәтүдән керем алу күздә тотылмаганны раслый торган документ;

к) Гариза бирүченең инвестицион проектын гамәлгә ашыру хезмәткәрләрнең гомуми саныннан 25 проценттан арткан күләмдә чит илдән килгән эшче көчләрне җәлеп итүне күздә тотмаганны раслый торган документ.

4. Гариза кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат саклау җайланмасында ике нөсхәдә тапшырыла. Гариза бер яки берничә папкага (томга) беркетелгән, аңа битләр саны һәм мөһер куелган булырга тиеш. Беренче булып Гариза һәм, тиешле документ урнаштырылган бит санын күрсәтеп, Гариза составына кергән документлар беркетелергә тиеш. Гариза составына берничә папка (том) кертелсә, папкалар (томнар) саны һәм һәр папкада (томда) тиешенчә битләр саны күрсәтелә.

5. Башкарма комитет Гаризаны алган көннән 10 эш көне эчендә Гаризаны карап тикшерә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Гаризаны кире кагу;

Гаризаны кабул итү.

6. Гаризаны кире кагу турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

а) әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында каралган документларны кертмәү;

б) Гариза бирүченең, Гариза бирүче гамәлгә ашыра торган инвестицион проектның яки Гаризаның норматив документлар һәм әлеге Тәртип таләпләренә туры килмәве;

в) Гариза бирүче салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә махсус салым режимнары кабул итү;

г) Гариза бирүче үзенең эшчәнлеген гамәлгә ашырырга планлаштыра торган алга киткән үсеш территориясеннән читтә Гариза бирүченең филиалы яки вәкиллеге булу.

7. Гаризаны кире кагу турында карар кабул иткән көннән өч эш көне эчендә Башкарма комитет бу турыда Гариза бирүчегә язмача хәбәр итә. Башкарма комитет Гаризаны кире кагу турындагы карарында Гаризаны кире кагуның мотивлаштырылган нигезләрен күрсәтергә тиеш. Башкарма комитетның Гаризаны кире кагу турындагы карарына законнар белән билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелә ала.

8. Гаризаны кире каккан очракта, Гариза бирүче, Башкарма комитетның хәбәрнамәсендә күрсәтелгән кимчелекләрне бетергәннән соң, аны кабат җибәрергә хокуклы.

9. Гаризаны кабул итү турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет әлеге карарны кабул иткән көннән өч эш көне эчендә:

Гариза бирүчегә бу турыда хәбәр итә;

Гаризаның бер нөсхәсен кәгазьдә – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм электрон рәвештә – Гариза бирүченең Гаризада күрсәтелгән инвестицион проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә тормышка ашырырга планлаштырыла торган икътисадый эшчәнлек төре аларның эшчәнлек өлкәсенә караган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына (алга таба – министрлыклар) җибәрә.

10. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм министрлыклар Гаризаны карап тикшерәләр һәм Гариза бирүченең инвестицион проекты бизнес-планына түбәндәгеләр буенча анализ ясыйлар:

инвестицион проектны тормышка ашырганда хәл ителә торган бурычларның Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш бурычларына, шулай ук тармак үсеш стратегияләре (программалар, концепцияләр) өстенлекләренә туры килүе;

инвестицион проектны тормышка ашырудан уңай социаль, икътисадый нәтиҗә һәм бюджет нәтиҗәсе булу.

11. Бизнес-план анализы түбәндәге күрсәткечләргә мөнәсәбәтле гамәлгә ашырыла:

а) күрсәтелгән инвестицияләр күләме;

б) үз акчасы һәм заем акчасы, аларның чагыштырмасы;

в) инвестицион проектны гамәлгә ашыра башлаганнан соң 10 ел эчендә аны тормышка ашыру нәтиҗәсендә кертеләчәк дәүләт бюджеттан тыш фондларга салым керемнәре һәм кертемнәренең суммасы;

г) аны гамәлгә ашыра башлаганнан соң 10 ел эчендә булдырылган инвестицион проектка өстәмә кыйммәт;

д) булдырыла торган эш урыннары саны;

е) норматив документларның максатларына һәм бурычларына туры килгән башка икътисадый һәм социаль күрсәткечләр.

12. Карап тикшерү йомгаклары буенча, Гаризаны алган көннән 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм министрлыклар Гариза

бирүченең инвестицион проектын гамәлгә ашыру максатка ярашлы булу (булмау) турындагы эксперт бәяләмәсен Башкарма комитетка җибәрәләр.

13. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм министрлыкларның бәяләмәләрен алганнан соң, Гариза алга киткән социаль-икътисадый үсеш территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турындагы килешүләрне карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) тарафыннан карап тикшерелә.

14. Комиссия составы һәм аның турындагы нигезләмә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән раслана. Комиссия составына Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, территориясендә алга киткән үсеш территориясе төзелгән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары, салым органнары вәкилләре, шулай ук башка мәнфәгатьле оешмалар вәкилләре керә.

15. Комиссия Комиссия рәисеннән – Татарстан Республикасы икътисад министрыннан, Комиссия рәисе урынбасарыннан – территориясендә алга киткән үсеш территориясе төзелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгыннан, Комиссия секретареннән – Башкарма комитет вәкиленнән һәм Комиссия әгъзаларыннан тора.

16. Комиссия утырышы кимендә айга бер тапкыр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм министрлыкларның эксперт бәяләмәләре белән Гаризалар булу шартында үткәрелә.

17. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Комиссия секретаре гамәлгә ашыра.

18. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы санала.

19. Комиссия утырышында Гаризасы карап тикшерелә торган Гариза бирүче вәкиле катнаша.

20. Утырыш барышында Комиссия Гаризаны һәм Гариза бирүче тарафыннан гамәлгә ашырыла торган инвестицион проектны түбәндәге критерийлар буенча, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм министрлыкларның эксперт бәяләмәләрен исәпкә алып бәяли:

а) Гаризада китерелгән мәгълүматларның нигезле булуы;

б) Гариза бирүченең инвестицион проектының әзерлек дәрәҗәсе;

в) Гариза бирүченең инвестицион проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле инфраструктура, куәтлелек һәм җир кишәрлекләре булу;

г) инвестицион проектны тормышка ашырудан уңай социаль, икътисадый нәтиҗә һәм бюджет нәтиҗәсе булу.

21. Гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

Килешү төзү мөмкинлеге турында;

баш тарту сәбәбен күрсәтеп, Килешү төзүдән баш тарту хакында.

22. Комиссия карары тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм аны кабул иткән көннән соң биш эш көне эчендә Комиссия беркетмәсе белән раслана. Комиссия беркетмәсе аны раслаган көннән соң өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм Башкарма комитетның сайтларында урнаштырыла. Карар тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителә.

23. Комиссия беркетмәсен раслаган көннән биш эш көне эчендә Комиссия кабул ителгән карар турында Гариза бирүчегә хәбәр итә.

24. Килешү төзүдән баш тарткан очракта, Гариза бирүче, Комиссия утырышы карарында күрсәтелгән кимчелекләрне бетергәннән соң, Гаризаны кабат җибәрергә хокуклы.

25. Уңай карар кабул иткән очракта, Башкарма комитет Килешү төзүне оештыра. Килешү Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Башкарма комитет һәм Гариза бирүче арасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган форма буенча төзелә.

26. Килешү төзегән көннән соң биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгына Килешү төзелгән юридик затны алга киткән үсеш территорияләре резидентлары реестрына (алга таба – Реестр) кертү өчен мәгълүмат бирә.

27. Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы Реестрга язма керткән көннән Юридик зат алга киткән үсеш территориясе резиденты (алга таба – Резидент) дип танылa.

28. Резидентны Реестрдан чыгару түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

а) Реестрга кертелгән Резидентның норматив документлар таләпләренә туры килмәве;

б) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына юридик зат – Резидент ябылу процессында булу турында язма кертү;

в) берләштерү, аеру, башка юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештыру яки яңадан оештыру нәтиҗәсендә юридик затның – Резидентның эшчәнлеген туктатуы;

г) юридик затны – Резидентны банкрот дип тану турындагы суд карары законлы көченә керү;

д) алга киткән үсеш территорияләре резидентлары гамәлгә ашыра торган инвестицион проектларга булган таләпләрне үтәп, аны тормышка ашыру мөмкинлеген калдырмый торган, Килешүдә каралган инвестицион проект параметрларның үзгәрүе;

е) юридик затның Килешү шартларын үтәмәве;

ж) Резидент инициативасы.

29. Әлеге Тәртипнең 28 нче пунктында күрсәтелгән шартлар турында Резидент өч эш көне эчендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Башкарма комитетка язмача хәбәр итә.

30. Резидентның эшчәнлеге туктау турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгына Резиденттан мәгълүмат алган көннән соң биш эш көне эчендә кертә.